# ГАБДРАХМАН САЛИХОВ

## I

Җыелды гәзитә мөхбирләре[1]. Арада зәһәр кара күзле бер яһүди, сары башлы, су күзле өч рус, киң йөзле, очлаеп килгән иякле ике татар бар.

Болар, үзләрен кабакның[*] башка кунаклары белән тигез күрмәгәнгә, аерым бер бүлмә алып, шау-шу белән шунда йирләштеләр. Бу халык күбрәк вакыт, эч пошканнан, бергә җыелып хәбәр сорашырга, ялганнар чыгарырга башка урын булмаганнан гына монда киләләр. Буфетчы марҗа бурычка бирүне дә туктатса, озын кич буена бер-ике пар белән үткәрәләр иде.

Бүген исә бөтенләй башкача күренәләр.

Шәһәрдә гәзитә галәме өчен теләгәнче кабартырга мөмкин бик зур вакыйга булып алды. Мөхбирләрнең һәркаюсы аны үзе эшли торган гәзитәгә язып, бер дә көтелмәгән йирдән һәммәсенең кесәләре кинәт кабарып ук китте.

Бүген шуның зәкятен бирергә — үзләре кабарткан куыкны пиво белән җуарга, шәпләп тибәргә уйлыйлар.

Буфет марҗасы Анна Тимофеевна, бурычларын түләмәгәнгә, гадәттә боларны эченнән: «Тагы җыелды инде бу бушбугазлар», — дип каргап, тышыннан караңгы йөз күрсәтеп каршы ала иде. Күптәнге тәҗрибәсе белән бүген ул бу гөруһның[2] котырачагын, котырырлык чамалары барлыгын сизенде. Һәрберсен аера-аера туктатып, мөхбирләрнең тамагын туйдырган зур вакыйга турында үзенең фикерен сөйләгән булып, аерым илтифатлар күргәзде. «Залда кеше күп, теләсәгез, бүлмә бирергә мөмкин», — дип хезмәт гарыз кылды[3]. Шаулашып бүлмәгә кереп тә йиттеләр, артларыннан кергән ак алъяпкычлы официантка:

— Китер каз!

— Китер йомырка!

— Китер папирос!

— Китер бер дюжина столовое пиво! — дип, төрле яктан акырышып һөҗүм дә кылдылар.

Официант ташып өлгерә алмый: килгән казлар коры сөякләрен калдырып оча тора, йомыркалар югала тора, «пиво, пиво» дигәнең инде эсселектән көйгән сахра комына түгелгән су шикелле кәрзине-кәрзине белән сеңә генә бара.

---

[1]*Мөхбирләре*— хәбәрчеләре.

[*]1916 елгы басмада *кабак* сүзе *мәйханә* сүзе белән бирелгән.

[2]*Гөруһның* — төркемнең.

[3]*Хезмәт гарыз кылды* — хезмәтен тәкъдим итте.

Бер сәгать үтмәде, йомшагракларның күзләре канлана да башлады. Киң җилкәле, эштән чыгып каралган кәгазь якалы калын рус — Ваня урыныннан торды да, ихтыярсыз җәелеп барган киң авызын тагын да җәя төшеп көлеп, ач күзле, хәйләкәр йөзле татар егетенең каршына барып, иптәшчә аның аркасына сукты:

— Ну, Абдул, син бер зур материалым бар, сезгә бүген татар психологиясенең кызык бер чертасын сөйлим дигән идең; исереп өстәл астына ауганчы ялганлап кал, диде.

Башкалар да:

— Абдул, чынлап та, сөйлә әле... Синең ялганнарны ишетмәгәнгә байтак булды, — диештеләр.

**II**

Яңадан каз килде, йомырка килде, шул арада пиво түгелеп пычранып өлгергән ашъяулык алыштырылды. Һәммәсе бик шат чәкәшеп, стаканнарны, төбенә чаклы бушаткан соң, Абдул сөйли башлады:

— Мин, — ди, — бер көн төнге тибүдән соң авылга барган идем. Шунда кызык нәрсә очрады. Электән бераз таныш булган Садыйк мулла миңа бик зур иттереп тәрилкә тота, сыйлый, атлары белән сахраларга алып чыга, үзенең әллә нинди эшләрен сөйли. Мин боларның бушка булмавын баштан ук сизендем. Бу карт төлке, дим, юкка боргаланмыйдыр бу, дим, мине үзенең берәр этлегенә корал итәргә уйлыйдыр, дим... Һәм яңлышмадым. Китәсе көнне бу минем белән бигрәк артык якын да, дуст та кебек кыйланган булып, үзенең «милләт» юлындагы күп хезмәтләрен санады, дошманнарыннан зарланды, үзе турында «...» гәзитәсендә ялганнан яманлап язганлыкларын тәфсил итә[1] башлады. Мин аның кая тартканын сизәм, ләкин юри бернәрсә дә аңламаган булып утырам. Тагы, тагы алга, тагы эчкәрәк, дим. Ахрысы муллам түзмәде, яшерен серен тапшырган, шуның үтәлүе өчен ялварган бер кол кебек, үзенең эчендәгесен чыгарып салды: «Әгәр дә, ди, берәр мөнәсәбәт табып, исемемне, губерна һәм авылымны ачык әйтеп мине гәзитәдә мактасаң, ди, сине, ди, мәңге онытмам, ди; син, ди, дуст кеше... Әйе инде, анысы да калмасын, ди, мин, ди, аның өчен юл башына утыз тиенгә чаклы каләм ялы түләр идем», — ди...

Авылда яткан мулланыкы тагы бер хәл әле, егетләр, менә анардан да кызыграгы бар. Яңа фикерле, мөтәрәкъкый[2] карилардан (Коръәне хафизлардан[3]) берсе юлда туры килде. Ул минем бик якын дустларымнан.

---

[1]*Тәфсил итә* — аңлата.
[2]*Мөтәрәкъкый* — алдынгы фикерле.
[3]*Коръәне хафизлардан*— Коръәнне яттан белүчеләрдән.

Шул, — башы сау, тәне таза, хатыннарга идеал булырлык яхшы йөзе бар яшь егет — миннән «дустлык хөрмәтенә!» дип ялынып сорый: «Зинһар, ди, нинди дә булса бер гәзитәгә берәр турыда хәбәрме, мәкаләме яз да, шуңар мин имза куйыйм, минем исемем гәзитәдә басылып чыксын, ди; шуны эшләсәң, яхшылыгыңны мәңге яд кылыр[1] идем», — ди.

Абдул, сүзен бүлеп, стаканын ала да эчә башлый; иптәшләре кари белән мулла турында көлешәләр. Яһүди, уенмы, чынмы икәнен аеру читен бер тавыш белән:

— Шулай шул, әлбәттә шулай!! Кирәк бит ничек булса да матбугатка исем чыгарырга... — дип сөйләргә тотына.

Моңарчы сүзгә күп катышмый утырган икенче татар — Шәмси аягүрә баса да:

— Гәзитәдә мактатып шөһрәт чыгарырга теләгән: карт мулла белән кеше язган мәкалә астына имзасын куеп дан алырга теләгән кари әфәнде хәзрәтләре шәрәфенә бокал күтәрәм, — дип, һәммәсе белән чәкәштереп эчеп җибәрә.

Башкалар да аңа кушылалар, һәммәсе төбенәчә эчәләр.

Яңадан пиво килә. Абдул каз ботын кимереп, ялап, сөяген тәрәзәдән бакчага таба ата, яңа гына ачылган, күбекләнеп торган пивоны стаканга салып, бераз гына авыз итеп куя да:

— Болар артык мөһим түгел, аның менә тагы шәбрәге бар әле, — дип, сүзен дәвам иттерә.

**III**

— Бусы инде, — ди, — бөтен бер хикәя булырлык. Ачыграк аңлашылсын өчен иң элек хикәянең каһарманын сезгә тәкъдим итим. Озынча буйлы, төз, чандыр гәүдәле, каудар[2] табигатьле; тагы бер сыйфаты — тыштан ялтырап, үзенең бөтен ачлыгын, ярлылыгын кешегә белдерми яшерә, эченә җота торган бер яшь егет. Аның хакында һәммә иптәшләре: «Эче калтырый, тышы ялтырый», — диләр. Ул берничә көн ач тора ала, башка һәр нәрсәсен сата, әмма кулындагы кыйммәтле таягы белән спайлык өчен генә алынган яхшы пенснесен (күзлеген) дөнья йимерелсә дә сатмый: «Болардан мәхрүм калсам, мин үземне адәм түгел дип хис кыла башлыйм», — ди. Тагы бер сыйфаты калмасын: ул бездә саннары бик күп булган мәгълүм гөруһтан — русча укып дарелфөнүнгә[3], һич булмаса институтка керү, һич булмый икән, хәзергә генә учительлек хокукы алу өчен имтихан кылынуны үзенә максад

---

[1] *Яд кылыр*— искә алыр, онытмас.
[2] *Каудар* — кабаланучан, тынгысыз.
[3] *Дарелфөнүнгә*— университетка.

итеп куйган, шул юлда ата-анасын, бөтен рәхәтен, бөтен дөньясын ташлап йөргән яшьләр сафыннан бер гаскәрдер. Без аның белән Кинәле стансасында очраштык. Миңа сөйләгән хикәясенең факт булуында шөбһә итсәңез, кяфер булачаксыз.

«Миңа, ди, үткән җәйне дүрт ай «...» шәһәрендә татарлар эчендә яшәргә тугры килде. Менә ун еллар инде иртәге көндә ачка үлмәвемнән әмин була алганым[1] юк. Мин — ярлы торырга өйрәнгән кеше. Ләкин ул җәйдә шул чаклы ачыктым инде, аны Ходай явыз дошманыңа гына күрергә язсын. Майдан башлап сентябрьгәчә кесәм көмеш йөзе күрмәде. Нинди каһәрләр аркылы үтеп, берәрсеннән бурычка эләктерә алгансың икән — ул да минуты белән бетә. Фатирчы марҗа бугазыңнан буган, бурычка икмәк биреп торган күрше кибетче карчык үткән саен арттан кычкырып кала. Син инде, кулыңа берничә тиен керү белән, шул зобаниларның күзенә бәрергә тырышасың. Үземнең берничә кешедә аласым бар иде. Яз көне балалар укытып та бераз акча килер дип уйлаган идем. Ләкин алачакларны бирмәделәр. Балалар укытырга (ләгънәт төшсен шул гәзитәләргә!) икенче бер манигъ[2] чыкты. Кайдандыр бу шәһәрдә минем бер гәзитәгә мөхбир булып ятуым, көлке журналларында язучы булуым хакында бер хәбәр чыккан. Бу халык, нинди мантыйк[3] беләндер, балаларга сабак укыту белән гәзитәгә мөхбирлек итү, көлке журналларында язышуны бергә сыйдыра алмыйлар икән. Шул сәбәптән балаларын бирмәделәр. Бирмәсәләр, кадалып китсеннәр! Мин идеалым университет белән, барлык ач үткәргән, шунда да кешегә ялынырга теләмәгән мәгърур көннәрем белән ант итеп әйтәмен: гомеремдә матбугатка чыгарыйм дип бер юл язганым, мөхбирлек итим дип бер мәртәбә кулга каләм тотканым юк. Ул хәбәр баштанаяк ялган. Шулай да мин аның ялган икәнен игълан итәргә теләмәдем. Эчемдә бөтен туклар дөньясына ачу кайный. Шуларның бичаралыкларын, кызганычлыкларын битләренә бәрергә, шуларның ваклыклары өстеннән югарыдан торып хахылдап көләргә миңа ул хәбәр ярдәм итте. Ул туклар мине артымда шарлатан дип, кайдан килеп төште Ходаның бу каһәре дип сүгәләр икән. Теләгәнчә сүксеннәр, ләкин алдымда аларның берничәләре калтырады, берничәсе, үзенең яшерен эшләгән пычраклыгының матбугатка фаш булу ихтималыннан куркып, миңа ерактан кул кушырып сәлам бирә торган булдылар».

**IV**

— «Мин, ди, башта акчаның табылу ихтималына корып, бүлмәне

[1]*Әмин була алганым*— ышанганым, тыныч булганым.
[2]*Манигъ* — тоткарлык.
[3]*Мантыйк* — логика; монда: «нинди уй-фикер беләндер».

шәһәрнең эченнән, яхшырактан алган идем. Ачыккан саен, акча бирмәгән өчен марҗа беләнталашкан саен квартирдан күчә-күчә, шәһәрнең иң читенә, — шунысы яхшы тагы, — зур елгага каршы урамның иң начар бер өенә барып җиткәнмен... Фатир хуҗаларым тавык оясы чаклы гына бер кибет тотып маташкан мещаннар иде. Унҗиде яшьләрендә кызлары да бар. Матур гына, ягымлы гына бернәрсә. Минем өстемдә кара сатин күлмәк, билдә каеш, башта кепкы, кулда кыйммәтле таяк. Болар өстенә тагы яхшы пенсне дә элеп йибәргәч, марҗа кызына мин шәп кеше булып күрендем ахры. Ул минем мондый ае ике ярымлык начар бүлмәгә чыгуыма аптырады, аңа нинди дә булса бик тирән, бик серле бер сәбәп эзли башлады, ләкин таба алмыйча аптырый иде булырга кирәк: минем белән мөнәсәбәттә булуын яратмаган анасы кая да булса киттеме, Надя хәзер минем якка атылып чыга да, яшь өмит белән тулган матур күзләрен миңа текәп, матур елмая, теге үзе аңлый алмаган сер турында берәр сүз алырга тели иде. Бик зур бәхетемә каршы, фатир хаккын алдан биреп котылган идем, шуңа күрә Надя ул тирән серне кергән көннәрдә үк аңлап җитә алмады. Ләкин тиз арада аңа кайбер нәрсә ачыла башлады булырга кирәк. Ай үтмәгәндер, ул инде бөтен хикмәткә төшенеп житте. Шуның белән аның елмаюы әүвәлге чаклы ук матур күренми башлады, күзләре дә әүвәлге кебек яшь өмит белән тулып карамыйлар, ул хәзер бик гади бер урыс мещанының кызы булып калды.

Яңарак күчкән чакта чәйне хуҗалар белән бергә эчә идем. Бераздан, алардан аерылып, үз бүлмәмә китертә торган булдым. Тук мещан кашында адәмнең кыйммәте кесәсендәге акча белән үлчәнә. Хуҗалар белән бергә эчсәң, һич булмаса савытта чәең, кабып эчәргә шикәрең, ашарга күмәчең булырга кирәк. Боларның кайбер арада булмавы гаҗәп түгел. «Ах, каһәр төшкере*, ят та ачка үл: кесәдә чирек тиен акча юк, ә тамак ач», — дип мактану белән аны үткәрергә мөмкин. Ләкин көн дә шулай булып китсә, айлар буена шулай барса, мещан марҗалары синең мактануыңа эчтән кызганып, бичара дип карый башлаячаклар. Теләсә ничек карасыннар, тик эчләрендә сакласыннар иде. Ләкин ул лыгырдый башлады: «Урынга керергә кирәк иде, атаңа хат язсаң, әллә йибәрер иде; бурычка алырга бер дә иптәшең юкмыни?» — дип синең өчен кайгырырга тотына... Менә иң авыры... шул тук мещанның сине кызгану мәсьәләсеинде. Аңар түзмисең, горурың күтәрелә, нинди дә булса аны йир астына йибәрерлек берәр сүз ычкындырасың...

Тагы квартир эзләргә туры килә. Шундый мәшәкатьләрдән берьюлы котылу өчен мин, тышкы күлмәкләрнең берсен сатып, бүлмәгә бик алдырдым

---

*1916 елгы басмада *каһәр төшкере* урынында *шайтан екгыры* сүзләре килә.

да, бикләнеп, рәхәтләнеп эчә торган булдым... Сөйләшү буенча, иртә бер, кич бер — көненә ике самавыр тиеш. Аны бик аккуратно куйдыртам. Кайбер вакыт салырга бер тамчы чәй булмый, кабарга бер кисәк шикәр дә калмаган икән. Зарар юк, кадагы ике тиенгә алынган бик һәйбәт арыш икмәге бар, тоз теләгәнчә сипсәң дә җитәчәк. Яңлыш берәрсе килеп кермәсен өчен ишекнең бикләнеп җиткәнме, юкмы икәнен яңадан бер мәртәбә карыйсың да тоз сипкән икмәкне телем-телем бөгәсең. Сусасаң — самавыр алдында гөҗләп утыра, стаканы, бал калагы да китерелгән; кызартырга чәең, тәмләтергә шикәрең юк икән — анардан бер дә дөнья җимерелми; саф кайнар суның үзен генә эчүне сәламәтлек өчен файдалырак, диләр».

**V**

— «Озын җәй шулай үтеп бара. Беркөн фатир марҗам, йокылы күзен тырный-тырный, бүлмәмә керде дә миңа ультиматум бирде: «Берсекөнгә, ди, ике ай тула, дүшәмбе көн шул ике айның акчасын биреп бетермәсәгез, бүлмәне бушатыңыз», – ди. Марҗаны бүлмәмнән ничек куып чыгарганымны ачык хәтерләмим. Артык эш булганга охшамый. Самавырны ире кертте. Ул да ярым куркулы көлү белән тагы хатынының сүзен, ләкин инде йомшаграк сыйфатта кабатлады. Менә мәсьәлә! Менә сиңа аграрный вопрос! Ике тук мещан сүгенә икән — аларга ирек, теләгәнчә сүгенсеннәр. Ләкин үзем ни эшләргә? Бүлмәдән куалар икән — аның бәласе зур түгел, бар нәрсәңне бер букчага төреп сул култыгың астына тыгасың да, уң кулыңа таягың алып, чыгып китәсең. Ләкин кая барырга? Кайсы фатирга гына барсаң да, синең ачлыгыңның бөтен тарихын күзләреңнән укыйлар, синнән һич булмаса ярты айлыкны алдан сорыйлар, һич булмаса бер илле тиен задатка кирәк. Кесәдә җилләр уйный. Берничә талчукчы татар кереп: «Җә, тагын нәрсәң бар сатарга?» — дип чыктылар. Ни булсын, ни бар? Нәрсәләрнең иң кадерлеләре дә сатылып беткән. Өстәлемә генә түгел, бөтен хәятыма зиннәт биреп торган бер альбомым бар. Язмыш теләсә нинди хәлгә төшерер, ләкин мин Кәримәмнең төсе итеп саклаган ул бердәнбер хатирәмне сатарлык дәрәҗәгә җитмәм. Талчукчының күзе альбомга төшеп, шуны сатмыйсыңмы, диюе җанымны бик әрнетте, — моны шуңа ачынганга әйтеп үтәм. Талчукчыны озатып, тар, озын, ярым караңгы таш бүлмәмнең бер башыннан икенче башына кызу-кызу атлап йөри генә башлаган идем, кемдер тышкы ишекне ачты да: «Габдрахман Салихов монда торамы?» — дип кычкырды. Атылып чыксам, ни күрим: озын буйлы урыс почтальон повесткага ошаш бер нәрсә бирә. Башым шаулап китте, тәнем шатлык белән тулды. Ләкин бу шатлык озакка бармады, мине тагы өмит алдады: мин акча повесткасы дип уйлаган идем, ул, гөнаһ шомлык, телеграм булып чыкты. Бер иптәшем яз башы белән

Себергә сәүдә итәргә дип киткән, барып рәтләнгәч, миңа акча йибәрергә вәгъдә кыйлган иде. Телеграм шунардан икән: «Хәлем бик мөшкел, ничек кенә булса да ун сум акча йибәр!!» — ди. Атаң башы! Сиңа анда ун гына сум акча кирәк икән, — мин монда ун тиен өчен таш кисәргә ялланырга торам. Ачудан телеграмны ертып тәрәзәдән ташладым да, эчемдә кайнап, ташып барган әрнүле ачуга түзә алмыйча, ни дә булса очрамасмы дип, шәһәр бакчасына киттем. Анда бөтенләй икенче дөнья иде. Музыка күңелле көйләр уйный, ак кул егетләр ал яңаклы, кара күзле фәрештәләр тирәсендә сыргалананалар. Бакча тулы халык, һәммәсе шат; монда дөнья көлә, табигать моңы белән йөрәген рәхәтләндерә. Ул якка карамаска ничаклы, никадәр тырышсам да, күзем һаман буфетка таба тартыла. Анда зур өстәлләр тирәсенә җуан корсаклы, калын җилкәле мещаннар бик эре бүкәннәр булып пуф-пуф тын алып утыралар; эчләре тулы, тамаклары теләми; тик, ничек вакыт үткәрергә аптыраган кебек, кыйммәтле нигъмәтләр[1] белән кашык уйнатып маташалар. Ничаклы теләмәсәң дә, күз шуларга төшә. Ахыр түзмәдем, бакчаның кеше аз йөри торган югары башына таба киттем. Юлда бер кыз янында җуан гына бер адәмнең кулын бутый-бутый нидер сөйләп торганы күренде. Әллә бөтенләй башка турыда сөйләткәннәрдер, ләкин миңа ул ит мичкәсе бай бичара кызны үзенең бетмәс-төкәнмәс хайванлыгына корбан итәргә тозак корадыр шикелле тоелды... Агулы ачлык уе миемне ярып бара. Бакчаның бу башында башка адәм юк икән. Көзгә каршы саргая, ялангачлана башлаган биек агачлар арасыннан озын бер сукмак бар. Моны, бәлки, минем шикелле хәятның бөтен каһәрләренә каршы барып, үзе теләгәнчә яшәргә теләгәнлектән мәгълүм рамкалар эченә сыймаган, шуңар күрә һәр адымы таш диварлар кисеп үтү кадәр агыр булган ялгыз калган егетләр, минем хәзерге минуттагы хәлемә төшкән вакытларында дөньядан, адәмнән бизеп, ялгызы җәһәннәм утында көйгән чакларында йөри-йөри салганнардыр. Сул кулымда таяк, уңы белән, Достоевскийның мәҗнүннәре[1+] кебек, маңлаемнан салынып төшкән чәчемне учлап алганмын да, миемне ярып барган агулы ихтыяҗ зәһәре ачысында җанымны кая куярга белми, караңгы бакчада тар сукмакның бер башыннан икенче башына кызу-кызу йөрим. Мием кызып, йөрәгем, җаным арып эштән чыккач, йөрергә хәлем беткәч, өйгә кайттым; бүлмәмә кереп, кепкымны салып кына тора идем, кучер кыяфәтле бер адәм рөхсәтсез үк кереп ятлагандай бер рәвеш белән: «Габдрахман әфәнде Салихов сез буласызмы?» — диде. Аны күрүгә ачлык онытылды, гади һавалы кыяфәт үз урынына кайтты. Күзлек аша югарыдан

---

[1]*Нигъмәтләр* — ашамлыклар.

карадым: «Әйе, мин булам! Ни йомыш?» Кучер тагы ятлап килгән сабак рәвешендә тәкрар итте: «Сезне Рәхимҗан бай чәйгә чакырган иде...» Көләргә дә, ни эшләргә дә белмәдем, бер минутта зиһенемдә дөнья әйләнде, эчтәге иблис әкрен генә баш күтәреп: «Чү, егет, эш пешә!» — диде. «Ярый, хәзер барырмын» җавабы телгә килгәч, чак тотып калып, малайга: «Хәзергә эшем...» — ди башлаган идем, ул сүземне бүлде: «Бай сезне алырга ат җибәргән иде, мөмкин булса хәзер килсен дигән иде...» Мин тагы аяк тери төштем: «Юк, — дидем, — хәзер барасы йирем бар, берәр сәгатьтән соң шуннан кайтышлый керсәм керермен...»

Малай вәгъдәмне яңадан тәкрарлатып кайтып китте».

**VI**

— «Җан биргәнгә җүн бирә, диләр. Дөрестән дә бирә; ләкин кайвакыт аның биргәне шундый ачы истиһзалы[1] була ки, синең мәгърур җаның аның биргәненнән капкан икмәгеңне кире чыгарыр мәртәбәдә кызара. Вәгъдәмне биреп, малайны чыгаргач, мин үз алдыма чыннан да кызарындым. Дөньясы кабахәт, бөтен адәм баласы вак, түбән. Мин үзем дә шуларның берсемен!

Шәһәрдә минем матбугатта эшләвем хакында ялган хәбәр барлыгын әйткән идем; бичара Рәхимҗан байның миңа ат җибәрүе дә шуның ямьсез бер нәтиҗәседер. Ул — дүрт хатынлы, симез җилкәле бер буржуа. Шул дүрт өстенә аның берничә «ятим» кызны аерым номерларда «тәрбия» кылуы хакында күптән үк төрле легендалар бар иде. Ул гына җитмәгән кебек, яңарак вафат булган бер хәзрәтнең егерме яшьлек матур хатыны белән мөнәсәбәт саклавы хакында бөтен шәһәрдә идән астыннан бер хәбәр йөри башлады. Кичә Кадыйр мәзиннең капкасы төбендә берничә кеше арасында шул турыда сүз чыккач, мин түзмәдем: «Шундый подлецлар да кеше арасында[*] йөри бит... Шуларның тышкы маскаларын җыртып, эчләрендәге чын хайван сурәтләрен дөньяга чыгарырга адәм юк», — дип куйдым. Минем бу сүземдә һичбер тәһдит[2] тә, арткы максадлар да юк иде. Ләкин мине матбугат мөхбире, көлке журналда язышучы дип ышанып йөрүчеләр шул яктан аңлаганнар, арада байның якыннарымы, тәрилкәчеләреннәнме булган ахры. Алар минем сүземне зурайтып байга ирештергәннәр: сине яза икән, язган икән, рәсемеңне төшергән, бик харап көлке, ди, әллә нинди яман сыйфатлар тагылган, тиздән басарга йибәрергә тора, тик байның үзен күрәсе иде, болар ифтира[3] булмасын, фәлән дип әйтә имеш, дип кабартып

---

[1]*Истиһзалы* — көлүле, иронияле.

[*]1916 елгы басмада *кеше арасында* сүзләре урынында *адәм кыяфәтендә* сүзләре китерелә.

[2]*Тәһдит* — куркыту.

[3]*Ифтира* — яла ягу.

сөйләгәннәр. Ил гайбәте каршында дер калтырый торган җуан мещан берьюлы каушаган булырга тиеш ки, тәүлек үтүгә аның аты да минем капка төбенә килеп җиткән.

Малайдан соң үткәрелгән бер сәгать миңа җиңел булмады. Кичәдән бирле ашаган юк. Бүген иртә кибетче марҗа бер кадак арыш икмәге бирми чыгарды. Үзендә бик киң бил каешым рәһендә[1] ята, шулай да бирми: «Син, ди, әле дә күп алдың. Акчаңны түлә дә, каешың башыңа кадалсын», — ди. Эч тырный, күз алды караңгылана, йөрәк итен, әйтерсең, өзеп-өзеп алалар — шул дәрәҗәдә ашыйсы килә. Шундый вакытта килеп: «Сезне чәйгә чакырганнар!» — дигән адәмне кочаклап үбүдән, әйдә, хәзер киттек, дип, аның белән атылып чыгудан тыела алу — бу чыннан да бөек эш, ләкин моның бөеклеген тик, минем кебек, ул ач, мәгърур үткәргән көннәрнең ләззәтен татучылар гына белә алыр».

**VII**

— «Малайдан соң бер сәгать үтте. Алучы табылмаганга сатылмый калган иске учебниклар бар иде. Шуларны яхшы кәгазьгә төрдем дә, пенснене элеп, бер кулыма шул китаплар төргәген, икенчесенә кыйммәтле таякны тотып, бер дә сер бирмәслек кыяфәттә байга киттем. Ишек төбендә малай көтә иде. Кердек. Ни күрим: «Мең бер кичә»дә тасвир кылынган Һарун-әр-Рәшид сарайлары[2+] кебек зиннәтләнгән өйнең иң матур бүлмәсендә зур өстәл мин исемен дә ишетмәгән һәртөрле оҗмах нигъмәтләре, җәннәт ширбәтләре илә тулган. Уртада зур самавыр кайнап утыра. Мин шаша калдым. Бай, мине күрүгә, урыныннан сикереп торды да: «Рәхим ит... Рәхим итәсез...» — дип көлеп, кадерле кунак рәвешендә каршы алды. Утырыштык. Куллар ашамлыкларга сабырсызлык белән һөҗүм иттеләр. Ач бүрене мисалга алалар. Ләкин бу вакыт мин алардан артык бүре, алардан артык ач идем. Бераз ашагач, беркадәр тыелырга, гомеремдә икмәк йөзе күрмәгәндәй ачлыкны яшерергә тырышсам да, бай сизгәндер, дим. Чөнки никадәр әдәпле кылансам да, минем алдымда зур-зур өелеп утырган тәрилкәләр тиз арада ялаган кебек шома калалар иде. Минем һөҗүмгә илтифат итмичә, бай, кызганмас хаким алдында үзенең тәүбәсен укыган мәгъюб[2] кебек, үзенең мәрхүм хәзрәтнең кайгылы остазбикәсенә мөнәсәбәте нидән гыйбарәт икәнлеген сөйли башлады. Миңа андый юк-барны тыңлап торырга вакыт юк иде, тыңласам да, һичбер нәрсә аңлый алмас идем. Тик колагыма яңлыш кына кереп калган сүзләреннән аның хәзрәткә якын дуст булганын, мәрхүм

---

[1]*Рәһендә*— залогта.
[2]*Мәгъюб* — гаепләнүче.

үлем алдыннан моны чакыртып, кайбер эшләр тапшырганын, йорт, сәүдә йомышларына булышлык кылырга үтенгәнлеген, үлгәннән соң да хәзрәтнең өенә барып йөрүе тик мәрхүмнең тапшырган эшләрен үтәү өчен генә икәнлеген бераз төшендем.

Чәй янына тагы берничә сый кушылды. Утыра торгач, байтак вакыт үткән, мин соңгы стаканны эчеп куйганда, эчке бүлмәләрнең берендә сәгать унны сукты. Мин дә урынымнан кузгалдым. Бай өстәл башында минем каршыма килеп туктады, күп хәйлә кичергән майлы күзләре белән минем һәр ике күземә батырып туп-тугры карады да, уң кесәсеннән хәзерләп куелган маржа башлы күк кәгазьне чыгарып, бик җиңгел генә миңа төртте: «Сез, — ди, — шәкерт кеше... Сез әһле гыйлемсез[1]... Без үзебез укый алмагач, уку юлындагыларга ярдәм итәргә тиешлебез», — ди. Кулындагы кәгазьне күрү белән күзләрем ялтырагандыр, ләкин тәнемә салкын су коелган кебек булды, үзем ихтыярсыз артка чигендем: «Сез, — дим, — мине кемгә санадыгыз...» Ул мескенләнә төшеп иелде, баягы сүзләрен яңадан тәкрар итте. Нәтиҗәдә-минем горурым җиңелде; аңа кул бирми, саулашмый да чыгып китеп, авыр, салмак адымнар белән квартирыма кайтып, тимер караватка егылган вакыт шул мәлгунь кәгазь минем кесәмдә шытырдый иде.

Шул арада маржа кереп: «Әйтегез, бирәсезме, юкмы?» — дип кычкырды. Мин дәшмәдем, күтәрелеп карамадым, кесәдәге кәгазьне алдым да аңа таба ыргыттым: «Мә, кадал! Үзеңә дә кирәгеңне ал, кибетче карчыкка да минем бурычымны түләп, андагы каешымны алып кайт!!» Акчаны күрүгә хатынның күзе аларды, төшеме, өнеме дип кире чигенде, шулай да тиз генә эләктерде дә нинди гөнаһсы өчендер миннән гафу үтенә башлады. Мин аны куалап чыгардым да, ишегемне бикләп, шәмне сүндереп, бүлмәнең бер башыннан икенче башына йөри башладым.

**VIII**

— «Иртән сәгать унбердә, һич көтелмәгән вакытта Хәбиб кайтып килде. Ул бер гәзитә идарәсендә язучылыкта иде. Нашир беләнме, редактор беләнме талашкан да урынын ташлап чыккан икән. Ул — минем бик якын иптәш. Безнең аерылышуга дүрт айлар булды. Үзен сагынган минутлар да була иде. Шулай булса да, аны салкын каршы алдым, урынымнан тормадым, сузылып кул бирергә онытканмын. Ул минем мондый каршы алуыма гаҗәпләнде бугай. Һәрберсе йөрәгемне өзеп алып чыккан санаулы, авыр аз сүзләрем, нindидер хурлану эсәре белән караган күзләрем, басынкы һәм караңгы йөзем аның гаҗәпләнүен бигрәк арттырды булырга тиеш. Ишектән

---

[1] *Әһле гыйлемсез* — гыйлем ияләре.

кергәндә ачык, шат, җиңел күренгән Хәбибнең йөзе башта аптырау әсәре, аннан соң минем тәәссергә[1] кушылу төсе белән капланды да, чишенмичә үк, минем караватым янына килеп утырды: «Ни булды, сөйлә, иптәш!» Мин аңа кичәге вакыйганы сөйләп бирдем. Ул башта аңламады: «Биргән — алгансың, аның нинди хурлыгы бар?! Алар үзләре мең җанның маңлай хезмәте белән биек сарайлар салалар, — юкка бала булма», — дип, миңа каршы торып караса да, ахырдан шул нәтиҗәгә киленде: анарда бераз акча бар икән. Марҗа кичә биргән кәгазьне ваклап унике сумын тоткан. Шуны Хәбиб кесәсеннән тутырдык та, банкта кәгазьгә әйләндереп, Рәхим байга кире кайтардык...

Шуның белән йөрәгем җиңеләеп үк китте...»

---

Абдулның хикәясе шул йиргә җиткәч, залдан ак алъяпкычлы официант керде дә:

— Әфәнделәр, ябарга вакыт! — дип игълан кылды. Мөхбирләр урыннарыннан кузгала башладылар. Яһүди барыннан элек сикереп торды да:

— Дөньяда бар икән җүләрләр: алдый белгән, алганын ашарга җүне җитмәгән! — дип кычкырды.

Руслардан берсе, ава-түнә урыныннан күтәрелеп, стаканын кулына алды да:

— Ә мин, мин аны егет дим... Намус дим... Мин намус дим... Шул намус шәрәфенә эчәм, — дип, стаканын авызына каплады.

Яңадан пиво салып, чәкәштереп эчтеләр дә киенә башладылар. Кайберләре яхшы ук исергән иде. Яһүди авыз эченнән нидер мыгырдарга тотынды. Руслардан берсе, юешләнеп беткән сары мыегын ялый-ялый, подностагы пивога чумган папиросны алып яндырырга маташа.

Ишектә тагы официант күренде.

Зал якта ут сүнде.

Кемнеңдер бүреген таптаганнар. Яһүди яңлыш Ваняның калушын кигән.

Абдул, зал ягына чыгып, караңгыда нидер җырлый башлады. Аңа Шәмси дә кушылды. Тамаклары карлыккан, тавышлары исерек иде. Аларның:

Без эчәбез дә җырлыйбыз, акча бетсә урлыйбыз;
Безгә Ходай шулай язган, ярамый дип тормыйбыз, —

дигән җырларының ахырына яһүд катышкан булып, һичкемгә аңлашылмаган

---

[1] *Тәәссергә* — тәэсирләнүгә.

бер телдә кычкырынып китте.

Ут бүлмәдә дә сүнә.

Буфет марҗасы: «Тагы рәхим итегез», — дип, боларны исән-сау озату юлларын карый.

Исерек кунаклар да караңгы залдагы өстәлләргә абынып, урындыклар аударып, берсенә-берсе бәрелеп, җырлашып, кычкырышып, ава-түнә чыгып китәләр.

Кабак тына.